**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел.(85552) 3-44-22, факс (85552)3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

____________　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　______

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты вакантлы муниципаль вазыйфасын биләүгә конкурс турында

«Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясы, Актаныш муниципаль районы Советының «Актаныш муниципаль районында муниципаль хезмәт вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе турында» 2007 елның 1 августындагы 17/04 номерлы карары нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль сатып алулар һәм административ практика секторы мөдире вакантлы муниципаль вазыйфаны биләп торуга конкурс үткәрергә.
2. Расларга:

- конкурс комиссиясе составын, 1 кушымта нигезендә;
- конкурсны үткәрү шартларын, 2 кушымта нигезендә;
- конкурс комиссиясенең эш регламентын, 3 кушымтасы нигезендә;

3. Кадрлар белән тәэмин итү секторы мөдиренә Актаныш мәгълүмат порталының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында хәбәр урнаштыруны тәэмин итәргә..
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　Р.А.Ильясов

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
_______________ №___
карарына 1 нче кушымта

Конкурс комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Ильясов Р.А. | комиссия рәисе, Башкарма мкомитет җитәкчесе; |
| Вахитов И.Р. | Комиссия рәисе урынбасары, муниципаль район Советы Аппараты җитәкчесе (килешү буенча); |
| Сафина Л.Ф. | комиссия секретаре, оештыру бүлеге башлыгының кадрлар буенча урынбасары; |
| Гилаева М.З. | Муниципаль район Советының оештыру бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Сираева Л.Р. | Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад һәм фаразлау буенча урынбасары; |
| Шакирова А.М. | Эшләр идарәчесе; |
| Хәйдәрова Л.Г. | Башкарма комитетның гомуми бүлеге башлыгы; |
| Сәхбиева Г.Р. | Юридик бүлек башлыгы. |

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе
карарына ______________ №___
2 нче кушымта

Конкурсны үткәрү шартлары

Претендентларга квалификация таләпләре:

1) «дәүләт һәм муниципаль идарә» белгечлеге буенча югары профильле белем яисә:

муниципаль хезмәтнең муниципаль вазыйфасы яисә муниципаль вазыйфасы өчен тигез дип саналган белем яисә Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль сатып алулар һәм административ практика секторы мөдире.

2) Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты муниципаль сатып алулар һәм административ практика секторы мөдиренә белгечлек буенча эш стажы муниципаль вазыйфа өчен кимендә ике ел.

Конкурста катнашырга теләүче затлар конкурс комиссиясенә гариза бирә, аңа түбәндәге документлар беркетелергә тиеш:

1) 4 х 6 зурлыгында фото кушымтасы белән кулдан тутырылган һәм имзаланган анкета;

2) паспорт күчермәсе яки аны алмаштыручы документ (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән тапшырыла);

3) кирәкле һөнәри белем, эш стажы һәм квалификациясен раслаучы документлар:

- һөнәри белем турында, шулай ук гражданин теләге буенча өстәмә һөнәри белем бирү, гыйльми дәрәҗә бирү, эш (хезмәт)урыны буенча нотариаль яки кадрлар хезмәтләре тарафыннан расланган гыйльми исем бирү турында документлар күчермәләре;

- гражданинның хезмәт эшчәнлеген раслаучы хезмәт кенәгәсенең яисә башка документларның күчермәсе;

4) гражданда муниципаль хезмәткә керүгә яки аны узуга комачаулаучы авыру булмавы турында документ;

5) авторлык эшләре (гражданин теләге буенча).

Конкурс (документлар конкурсы, әңгәмә, һөнәри компетенцияне бәяләү): 2022 елның 6 маенда 10.00 сәгатьтә үткәрелә, гаризалар һәм конкурс документларын тапшыру вакыты:

Конкурс үткәрү турында хәбәр басылганнан соң 20 көн эчендә.

Гаризалар һәм конкурс документларын бирү урыны: 423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17, өченче кат, кадрлар бүлеге, тел./факс (85552) 3-44-25

Актаныш муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
_________________ № ___
3 нче кушымта

КОНКУРС КОМИССИЯСЕНЕҢ ЭШ РЕГЛАМЕНТЫ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Вакантлы муниципаль вазыйфаны биләп торуга конкурс үткәрү максатыннан Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль сатып алулар һәм административ практика секторы мөдире конкурс комиссиясе (алга таба - Комиссия) төзелә. Конкурс комиссиясе составы Башкарма комитет җитәкчесе карары белән раслана.

1.2. Комиссия үз эшчәнлеген Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль сатып алулар һәм административ практика секторы мөдире вазыйфасына дәгъвачыларны билгеләү турында Башкарма комитет җитәкчесе күрсәтмәсен бастырганчы башкара.

1.3. Конкурсны уздырганда комиссия федераль, республика законнарына һәм Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына каршы килми торган дәгъвачыларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларын куллана ала.

2. Комиссия утырышларын үткәрү тәртибе

2.1. Утырышны комиссия рәисе яки аны алмаштыручы зат алып бара.

2.2. Комиссия конкурста катнашу өчен тәкъдим ителгән документларны карый, әңгәмә үткәрә, конкурста катнашучыларның һөнәри һәм оештыру сыйфатын бәяли.

2.3. Комиссия утырышы, комиссия составының кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

2.4. Комиссия карарлары комиссия әгъзаларыннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм беркетмәдә чагылдырыла.

Тавышлар тигез булган очракта, комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

2.5. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре утырышта катнашкан рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм комиссия әгъзалары тарафыннан имзаланган карар белән рәсмиләштерелә.

2.6. Комиссия карары кандидат катнашыннан башка кабул ителә.

2.7. Вакантлы вазыйфаны биләп торуга конкурс нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет җитәкчесенең вакантлы вазыйфага конкурста җиңүчене билгеләү турында күрсәтмәсе чыгарыла һәм конкурста җиңүче белән хезмәт килешүе төзелә.